
**БЕЗ – МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ УКУЧЫЛАРЫ!**

# ТЫЛСЫМ+

**Мөслим гимназиясе укучылары газетасы**

***Гыйлемлелек** - инсаннарны мәңге яшәтә торган “тереклек суы” ул. Ансыз һөнәр дә, бәхет тә юк.*

*У.Имәни*




## Хөрмәтле укучыларым!

Кояшлы 1 сентябрь таңы безне кабат бергә жыйды. Мәктәпләрдә һәр бала көтеп алган, кызыклы вакыйгаларга бай булган яңа уку елы башланды. Күңелләрдә сөенеч, йөзләрдә шатлыклы елмаю балкый. Бүгенге көн бүләк иткән жылылык, көч һәм дәртне уку елы ахырына кадәр сүрелдермичә саклагыз.
Укытучы биргән белем-тәрбияне төкми-чәчми кабул итеп алыгыз,чөнки белемле кеше бүген меңне егып кына калмый, ә үзе теләгән уку йортына имтиханнарсыз укырга керү хокукына да ия була.
Гимназия укучысы дигән исемне горур йөртеп, яңадан яңа үрләргә омтылып, тырышып укырсыз, сезнең тырышлык белән Мөслим гимназиясе республикада гомуми белем бирүче инновацион уку йортлары арасында лаеклы үз урынын табар, дип ышанам.
Үзегезне, әти-әниегезне яңа белемнәрегез, алган "4"-"5" билгеләре белән көн дә куандырып торыгыз .
Яңа уку елында уңышлар, яхшы билгеләр, саулык - сәламәтлек, тырышлык, бәхетләр сезгә!

Гимназия директоры А.Ф.Мирзаянов



# Җәй-үзе кечкенә бер тормыш ул...




## БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

**Җәй файдалы уздымы?**

***Без, 8-10 нчы сыйныф укучылары, мәктәп яны хезмәт лагерында ял иттек. Быел бәрәңге гимназия бакчасында түгел, ә басуда үстерелде. Тырышлыгыбыз бушка китмәде: шактый уңыш җыеп алдык. Хезмәтебезнең нәтиҗәле булуы – барыбыз өчен дә шатлык!***

***Ильяс Ибраһимов***



**каникуллар**

**Кайда ял иттең?**

***Ә мин җәйге каникулларда әти-әнием белән диңгезгә бардым. Рәхәтләнеп йөздем, бассейнга йөрүемнең файдасы булды. Дусларыма диңгез төбе хәзинәләре дә алып кайттым.***

***Рената Харитонова***



**Мәктәпне сагындыңмы?**

***Мин һәр уку елы башлануын көтеп алам. Сыйныфташлар белән виртуаль аралашу гына җитми, тере аралашуга ни җитә!Безнең сыйныф укучылары – һәрберсе бер кызык дөнья! Кемнеңдер дәрестә булмавы шунда ук сизелә: нидер җитми башлый. Без бергә булганда, таләпчән укытучыларны да “эретә” алабыз, катлаулы хәлләрдән дә җиңел чыгабыз. Бердәмлектә – көч.Уку елын башлап җибәрдек, уңышлы ел булсын!***

***Сау бул җәй, исәнме мәктәп!***

***Камилә Ханеева***



**Җәйге яллар җитәрлек булдымы?**

***Быел җәй бик үзенчәлекле башланып китте...Беренче тапкыр имтиханнар бирү уен эш түгел шул.Әзерлек шул-кадәр арыткан, сынаулардан соң каядыр бару турында уйлыйсы да килмәде хәтта. И-и-и, туган якка җитәме соң! Каеннар белән серләшеп, үлән арасына яшеренгән кып-кызыл хуш исле җиләкләрне авыз иткәннән соң, үзеңне яңадан тугандай хис итәсең.***

***PS:Әле ярый бу уку елында имтиханнар тапшырасы юк...***

***Алсу Шәйхрамова***



# Т а н ы ш  б у л ы г ы з!  Б е з н е к е л ә р!

# *М О Г Җ И З А Л Ы  «Ө Ч Л Е К»*

**Кашапова Илүзә Ринат кызы**



**Туган елы: 2000**
**Йолдызлыгы: Кыз**
**Яраткан шөгыле: төрле халык биюләре**
**Хыялы: артист булу**
**Кумирлары: Екатерина Волкова, Роман Курцын, Ләйсән Мәхмүтова**
**Соңгы уңышлары: “Илһам” яшь язучылар бәйгесе – 3 нче дәрәҗә Диплом, 5000 премия, Бөтенроссия “Ак җилкән”яшь язучылар бәйгесе – [illegible]че урын, 2000 пр[illegible]я**

**Әһлиуллина Язилә Фиргать кызы**



**Туган елы:2000**
**Йолдызлык: Балык**
**Яраткан шөгыле: халык җырларын башкару**
**Яраткан фәне: биология**
**Хыялы: киләчәктә яңа ачышлар ясау, күренекле кеше булу**
**Уңышлары: Бөтенроссия ФПК 3 нче дәрәҗә Диплом; математика һәм химия буенча республика олимпиадасында катнашу**

**Харитонов Риназ Владислав улы**



**Туган елы: 1997**
**Йолдызлык: Кучкар**
**Яраткан шөгыле:  йөзү спорты**
**Хыялы: тәртип сакчысы булу**
**Риназны кайда очратырга мөмкин: “Нептун” бассейны**
**Нинди кешеләрне яратмый: үз эченә бикләнгән кешеләрне**
**Кешеләрдәге нинди сыйфатны әһәмиятле дип саный: тугрылык**
**Кумиры: әтисе Владислав**

# Котлыйбыз!

*Хөрмәтле мөгаллимнәребез!*

*Сезне **ЯҢА УКУ ЕЛЫ һәм УКЫТУЧЫЛАР көне белән** ихластан кайнар котлыйбыз!.*

*Сезгә корычтай нык сәламәтлек, гаилә бәхете,*
*һәр туачак таңга сөенеп, имин тормышта*
*яшәвегезне теләп калабыз.*

*Сезгә карап сокланабыз һәрчак*
*Күңелләрдә туа горурлык.*
*Рәхмәт сезгә, әле ярый сез бар*
*Безгә үрнәк булып торырлык!*

*Яраткан укучыларыгыз*

# Иң яхшы укытучы-2014

Республикакүләм **“Безнең иң яхшы укытучы” грантына** лаек булган укытучыларыбызны чын күңелдән уңышлары белән котлыйбыз.

Арсланова Лариса Николаевна, Хәйруллина Чулпан Алмазовна, Тимергалиева Эльмира Василовна, Шәнгәрәева Зөлфирә Насиховна, Юлдашев Илдар Наилевич, Фәрхетдинова Резеда Рөстәмовна, Асылгараева Глүсә Әскатовна, Мортазина Солтания Мәхмүтовна, Госсамова Рәмилә Сабирҗановна, Саяхова Зөлфирә Мухаровна, Идиатуллина Маргарита Александровна, Бариева Ләйсән Фәһимовна, Кадырова Римма Гайсовна!

*Дөньядагы һәрбер яхшылыктан*
*Өлеш чыксын сезгә мул гына.*
*Без телибез сезгә ак бәхетләр,*
*Шатлыкларга илткән юл гына.*

# Редактор сүзе

***Хөрмәтле укучылар! Сез үз газетагызны нинди итеп күрергә телисез? Газетаны кызыграк итәсегез киләме? Теләк-тәкъдимнәрегезне һәрвакыт кабул итәбез.***

***Оригиналь идеяләреңне безгә язып җибәр:http://sprashivai.ru/Tilsim2014***

## Пресс-группа

Ибраһимов Ильяс
Ханеева Камилә
Шәйхрамова Алсу
Тимергалиева Эльмира Василовна
Гамәлгә куючы: Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге.
Адрес: Мөслим, Кооператив урамы, 170-а йорт.
Сентябрь, 2014 нче ел